**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫН ХӘЛ ИТҮ**
**2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**
**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Урсай авыл җирлегенең Урсай торак пунктында**

2025 елның 12 ноябре № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Уставы нигезендә

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Урсай авыл җирлеге Урсай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, шул исәптән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем Инвалидларыннан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- Торак пункт территориясен төзекләндерү (спорт һәм балалар мәйданчыгын төзекләндерү);
- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту ( юлга вак таш салу).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) 7 көн дәвамында (Урсай авыл җирлеге Уставының 69 п.5 статьясы) кабул ителгән көннән..

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Урсай авыл җирлеге башлыгы Гатина Н.А.